ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.12.2021 п.г.т.Алексеевское № 434

**«Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган җирле бюджеттан финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 01 июлендәге 549 номерлы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 30 октябрендәге 1029 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

**карар бирәм**:

1. «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы исәпләнә торган җирле бюджеттан финанслана торган оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2011 елның 01 июлендәге 549 номерлы карарына (Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2011 елның 2 ноябрендәге 796 номерлы, 2012 елның 12 ноябрендәге 899 номерлы, 2013 елның 25 октябрендәге 836 номерлы, 2015 елның 24 апрелендәге 200 номерлы, 2015 елның 5 ноябрендәге 453 номерлы, 2016 елның 4 июлендәге 283 номерлы, 2017 елның 24 августындагы 330 номерлы, 2018 елның 22 февралендәге 41 номерлы карарлары нигезендә расланган үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

2 пунктның икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

күрсәтелгән карарга кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (Кушымта).

2. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе О.Н. Леденцовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.А.Гайнуллин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының
2021 елның 02 декабрендәге
434 номерлы карарына
кушымта

Җирле бюджеттан финанслана торган бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)

| Бердәм тариф челтәре өчен түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0000 | 13 617,0 |
| 2 | 1,0178 | 13 860,0 |
| 3 | 1,0362 | 14 110,0 |
| 4 | 1,0538 | 14 350,0 |
| 5 | 1,0736 | 14 620,0 |
| 6 | 1,0927 | 14 880,0 |
| 7 | 1,1133 | 15 160,0 |
| 8 | 1,1331 | 15 430,0 |
| 9 | 1,1530 | 15 700,0 |
| 10 | 1,1743 | 15 990,0 |
| 11 | 1,1948 | 16 270,0 |
| 12 | 1,2168 | 16 570,0 |
| 13 | 1,2389 | 16 870,0 |
| 14 | 1,2609 | 17 170,0 |
| 15 | 1,2837 | 17 480,0 |
| 16 | 1,3072 | 17 800,0 |
| 17 | 1,3307 | 18 120,0 |
| 18 | 1,3549 | 18 450,0 |

Искәрмә. Җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1 – 2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.